# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАКЫРЧЫАВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ КАРАРЫ

**“Бакырчы авыл җирлегендә кайбер оешмалар һәм объектлар янәшәсендәге алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган территорияләрнең чикләрен билгеләү турында” карарны үз көчен югалткан дип тану хакында**

2026 ел, 22 гыйнвар №11

Татарстан Республикасы Апас районы прокурорының протесты нигезендә һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату һәм алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган янәшәдәге территорияләр чикләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләү Кагыйдәләрен раслау турында" 2020 елның 23 декабрендәге 2220 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Бакырчы авыл җирлеге Советы карар итте :

1. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Бакырчы авыл җирлеге Советының “Бакырчы авыл җирлегендә кайбер оешмалар һәм объектлар янәшәсендәге алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган территорияләрнең чикләрен билгеләү турында” 2013 елның 17 июнендәге 75 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

Бакырчы
авыл җирлеге башлыгы Ф.Х.Валиев